# ТУГАН ӘДӘБИЯТ ПРЕДМЕТЫ БУЕНЧА КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘР

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Төп гомуми белем бирү баскычын төгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда туган телгә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
– “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Төп белем бирү баскычында туган тел һәм әдәбиятны укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисселек, эмпатия хисләре);
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
– әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Укытуның шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре:**

- укучыларда үткәнебезгә, тарихыбызга карата игътибар тәрбияләү;
- белемгә омтылыш тәрбияләү;
- белем алырга, кешеләргә файда китерергә, игелекле булырга омтылу.
- табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту, яхшылык эшләргә өндәү;
- ата-анага, олыларга карата хөрмәт тәрбияләү;
- кешелеклелек, намуслылык, гаделлек сыйфатларына карата хөрмәт тәрбияләү;
- хезмәткә, хезмәт кешесенә ихтирам тәрбияләү;
- укучыларда бер-берләренә карата ихтирам, дуслык хисләре тәрбияләү, әдәплелек кагыйдәләрен төшендерү.

5 нче сыйныф

**Туган әдәбият дәресендә укучы түбәндәгеләргә өйрәнә:**

- сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- классик әдипләрнең биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;

**Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**

- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;

аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һәм башкалар аша эзләү.

6 нчы сыйныф

**Туган әдәбият дәресендә укучы түбәндәгеләргә өйрәнә:**

- сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- классик әдипләрнең (Һ.Такташ, Ш.Маннур, М.Гафури, Ә.Еники, М.Мәһдиев)
- биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;

**Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**

- өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һәм башкалар аша эзләү.

7 нче сыйныф

**Туган әдәбият дәресендә укучы түбәндәгеләргә өйрәнә:**

- сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- классик әдипләрнең биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;

**Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**

- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;

аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һәм башкалар аша эзләү.

8 нче сыйныф

**Туган әдәбият дәресендә укучы түбәндәгеләргә өйрәнә:**

- сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- классик әдипләрнең (Г. Афзал, Ф.Садриев, М.Әгъләмов, Т.Миңнуллин) биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;

**Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**

- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;

аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һәм башкалар аша эзләү.

9 нчы сыйныф

**Туган әдәбият дәресендә укучы түбәндәгеләргә өйрәнә:**

- сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- классик әдипләрнең биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;

- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү;

**Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**

- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һәм башкалар аша эзләү.

**УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ**

5 нче сыйныф

Федераль базис укыту планында каралганча, 5 нче сыйныфта туган тел әдәбиятын өйрәнүгә атнасына 1 сәгать исәбеннән елга 35 сәгать бирелә, бу Татарстан Республикасының базис укыту планына туры килә. Программа ФДББС таләпләренә нигезләнеп эшләнелде.

Укучылар урта сыйныфларда халык авыз иҗаты әсәрләреннән әкият жанрын өйрәнә башлыйлар XIX, XX йөз әдәбиятларыннан иң яхшы әсәрләр белән, язучыларның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышалар. Сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә, бәйләнешле сөйләмнәрен, иҗади эш күнекмәләрен ныгытуга махсус рубрикалар бирелә.

Программаның эчтәлеге түбәндәге бүлекләрдән тора һәм әлеге бүлекләр буенча үтәлергә тиешле минимумны чагылдыра.

**Борын- борын заманда (5)**. Фольклор – халыкның коллектив иҗат җимеше. Анда халыкның теләк-омтылышының чагылышы. Фольклорның вариантлы булуы. Фольклор әсәрләренең төрләре, жанрлары. Балалар фольклоры (бишек җырлары, табышмаклар, тизәйткечләр һ.б.). Фольклор. Халык авыз иҗаты. Татар халык әкиятләре. Халык прозасының бер төре буларак әкиятләр. Әкиятләрнең хайваннар турында, тылсымлы, тормыш-көнкүреш төрләре булуы. Әкиятләргә салынган мәгънә. Татар халык әкияте «Өч кыз». Рус халык әкияте «Төлке белән Алёнушка».

**Әкият яздым, укыгыз (5).** Халык әкиятләреннән үсеп чыккан автор әкиятләре турында мәгълүмат. Аларның уртак һәм аермалы яклары. Автор әкиятләрендә халык әкиятләренең мотивлары, образларының үстерелеше.

Каюм Насыйри. Тормыш юлы турында мәгълүмат. «Патша белән карт» әкияте. Халыкның бер вәкиле булган тапкыр карт образы, аның зирәклеге.

Габдулла Тукай. Әдип турында мәгълүмат. «Су анасы» әкият-поэмасы. Әкият-поэмада кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре. Су анасы мифик образы. Әсәрдә малай образының бирелеше, аңа салынган мәгънә.

**Белем баскычлары (5).** Белемгә омтылу. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе турында мәгълүмат. Мәдрәсәнең 1882 нче елда Казанда ачылуы. Анда белем алучыларның шәкертләр дип аталуы. Казанның Татар укытучылар мәктәбе турында мәгълүмат.

Казан университеты турында мәгълүмат. Аның 1804 нче елның 17 нче ноябрендә ачылуы. Анда Карл Фукс, Илья Березин, Николай Лобачевский эшләве. Анда белем алган атаклы кешеләр. Хәзер аның Казан (Идел буе) федераль университеты дип аталуы.

**Балачак — хәтерләрдә мәңге калачак (5).**Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәреннән өзек. Әсәрдә кечкенә Тукай образының бирелүе. Автобиографик әсәр герое белән Тукай арасында уртак һәм аермалы яклар. Кечкенә Габдулланың Хаҗиморат Казаковның «Бәләкәй Апуш» картинасында сурәтләнеше. Габдулла Тукайның Кырлайдагы музее. Музей урнашкан төбәк. Андагы истәлекле экспонатлар.Теоретик мәгълүмат. Мемориаль комплекс.

**Ватаным өчен (5).** Муса Җәлилнең «Сагыну», «Соңгы җыр» шигырьләре. Аларга салынган хисне аңлау. «Алтынчәч»либреттосыннан өзек өйрәнү. Либреттоның әкияткә һәм дастанга нигезләнеп язылган булуы. Аның төп каһарманнары: Тугзак ана, Җик, Алтынчәч. Нәҗип Җиһановның либреттога музыка язуы. Композиторның иҗаты. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры турында мәгълүмат.

Фатих Кәримнең «Кыр казы», «Ватаным өчен», «Сөйләр сүзләр бик күп алар...» шигырьләре. Аларда Туган илне саклау, ярату хисләренең салынган булуы.

**Кояшлы ил – бәхет иле (5).** Нәби Дәүлинең «Бәхет кайда була?» шигырендә бәхет эзләү һәм табу кебек фәлсәфи мәсьәләнең чишелеше. Лирик герой өчен бәхетнең үзе яшәгән җирдә булуы. Теоретик төшенчә. Шигырь. Ритм. Рифма.

Фатих Хөснинең «Чыбыркы» хикәясе. Автор турында белешмә. Хикәядә малайның үз эшләре өчен җавап бирүе. Авторның бала психологиясен ачу үзенчәлеге.

Мәгъсүм Хуҗинның «Туган көн» хикәясе. Олыларга игътибарлы булырга өйрәтү. Кешеләрнең күңелен күтәрү - зур бәхет булуын ачыклау.

**Кеше – табигать баласы (3).** Мөдәррис Әгъләмовның «Матурлык минем белән» шигыре. Матурлыкны табигатьтән эзләү мотивы. Табигатьнең кешеләргә мәрхәмәтле булуы, аны сакларга кирәклеген төшендерү.

Рәссам Иван Иванович Шишкин иҗаты. Аның Татарстан белән бәйле язмышы. Иҗаты. Елның дүрт фасылы. Аларның һәрберсе үзенчә матур булуы.

**Эш беткәч көләргә ярый (2).** Теоретик төшенчә. Юмор. Шәүкәт Галиевның «Ул кем?» «Әллә кем», «Мәрзия мәсьәләсе» шигырьләре. Шагыйрьнең табышмак, юмористик шигырьләрендә бала хисләренең ачылышы.

**Әдәби әсәрләр минимумы**

К. Насыйри, "Патша белән карт"әкияте;
Г. Тукай, "Су анасы" әкият-поэмасы;
М. Җәлил, "Алтынчәч" (либреттодан өзек);
Ф. Кәрим, "Кыр казы" шигыре;
Ф. Хөсни, "Чыбыркы" (хикәясеннән өзек);
М. Әгъләм, "Матурлык минем белән" шигыре;
Н. Дәүли, "Бәхет кайда була?" шигыре.

**Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр:**

Дәрдемәнд. "Кил, өйрән..."
Ф.Кәрим. "Сөйләр сүзләр бик күп алар..."
Әхмәт Рәшитов. Кояшлы ил — бәхет иле.
Р.Фәйзуллин. "Табигать кочагында".

Эш программасын тормышка ашыру өчен Россия Федерациясенең Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләр исемлегендә түбәндәге дәреслек күрсәтелә: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 5нче с-ф. Ике кисәктә. 1,2 нче кисәкләр / Ә.Р.Мотыйгуллина Р.Г.Ханнанова, Л.К.Хисмәтова; [рәссамы Диләрә Нәүрүзова] Казан: "Мәгариф – Вакыт" нәшр., 2014.

Бу дәреслекнең ФДББС гриф тамгасы бар һәм ул Россия Федерациясенең Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләр исемлегенә кертелгән, Татарстанның Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан кабул ителгән.

## 6 нчы сыйныф

**1. Мифлардан чынбарлыкка (2)**

**Халык авыз иҗаты.** Әдәбият теориясе. Фольклор. Халык авыз иҗаты. Фольклор – халыкның коллектив иҗат җимеше. Анда халыкның теләк-омтылышының чагылышы. Фольклорның вариантлы булуы. Фольклор әсәрләренең жанрларын гомуми күзаллау. Балалар фольклоры (бишек җырлары, табышмаклар, тизәйткечләр, мәкальләр һ.б.). Башка халык авыз иҗаты белән чагыштыру.

**Мифлар. Татар халык мифлары.** Шүрәле», «Шүрәлене ничек алдарга?» «Су иясе», «Өй иясе», «Дедал белән Икар» мифлары. Мифларны өйрәнгән галимнәр. Әдәбият теориясе. Миф. Мифик геройлар.

**Мәкальләр һәм әйтемнәр.** Мәкальнең акыл бирү, сөйләмне матурлау өчен кулланылуы. Мәкальләрнең тематикасы. Әйтемнең күчерелмә мәгънәдә кулланылган, сөйләмнең эмоциональ көчен арттыра торган жанр булуы. Мәкаль белән әйтемнең аермасы. Татар мәкальләре һәм әйтемнәренең русча эквивалентлары. *Әдәбият теориясе. Мәкаль, әйтем.*

**2. Халык моңнары: җырлата да, елата да... (4)**

**Халык җырлары.** Халык җырларының авторы халык булуы. Аларның вариантлылыгы. Халык җырларының жанрлары. Йола җырлары, аларның килеп чыгу үзенчәлеге. Йола бәйрәмнәреннән Сөмбелә бәйрәме. Уен җырлары. **"Кәрия-Зәкәрия"** җыры. Шагыйрьләрнең кайбер шигырьләре халык тарафыннан көйгә салынуы. Г.Тукайның "Туган тел" шигыре. Аның төрле телләргә тәрҗемә ителүе. **Г.Тукайның "Туган авыл"** шигыре. Аның дә халык җыры кебек яратып җырлануы, киң таралган булуы.

**Татарстан Республикасы гимны.** Гимнның дәүләт символы булуы. Гимн уйнала торган очраклар. Гимнны тыңлау тәртибе. Татарстан Республикасының Дәүләт гимны авторлары Р.Байтимеров, Р.Яхин. Гимн текстының эчтәлеге, көе.

**3. Кадерле син, кеше-туганым! (13)**

**Нәкый Исәнбәт.** Язучы турында кыскача белешмә. “Өч матур сүз” шигыре. Әти-әни, туган илнең кадере. Шигырьдәге лирик герой. Шигырьнең диалог формасында язылуы. Шигырьнең Г.Тукайның “Туган тел” шигыре белән аваздашлыгы.
**Мәҗит Гафури.** Әдип турында кыскача белешмә. “Ана” шигыре. Шигырьдә ана өчен бала, бала өчен ана кадере. Н.Исәнбәт шигырьләре белән аваздашлыгы. Бишек җырларының әһәмияте турында мәгълүмат.
**Габдулла Тукай.** Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат. “Шүрәле” әкият-поэмасы. Әкият-поэмада кеше һәм табигать мөнәсәбәтләре, туган авыл табигатенең матурлыгы. Шүрәле мифик образы. Әсәрдә егет һәм Шүрәле образларының бирелеше, аларга салынган мәгънә.
**Фәрит Яруллин.** Композитор турында белешмә. “Шүрәле” балеты**.** Г.Тукайның «Шүрәле» әкият-поэмасына балет язылу. Балет авторлары Ф.Яруллин, Ә.Фәйзи, Л.Якобсон турында мәгълүмат. Былтыр, Шүрәле образларының бирелеше. Сөембикә образы, аңа салынган мәгънә. *Әдәбият теориясе. Балет.*
**Муса Җәлил.** Шагыйрьнең тормыш юлы, сугыш чоры иҗаты, “Моабит дәфтәрләре” турында мәгълүмат. М. Җәлилнең музей-квартирасы. **“**Чәчәкләр” шигыре**.** Шигырьнең язылу урыны, вакыты. Шигырьдәге символлар. Ччәкләрнең матурлык һәм үлемсезлек символы буларак бирелүе. Туган илне ярату, туган илне саклау идеясе. *Әдәбият теориясе. Символ, строфа.*
**Әмирхан Еники.** Әдип турында кыскача белешмә. “Туган туфрак” хикәясе**.** Әсәрнең төп идеясе. “Нигез”, “туган туфрак” төшенчәләре. Авыл табигатенең, авыл халкының бирелеше. Хикәядәге символлар. Клараның эчке кичерешләре. Авыл проблемалары.
**4. Энҗе карлар явып үткән... (3)**
**Галимҗан Ибраһимов.** Әдип турында кыскача белешмә. “Кар ява” хикәясе**.** Кышкы табигать, кар яву күренешенең тасвирлануы. Хикәядә чагыштырулар.
“Чыршының күлмәкләре” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы. “Нәни чыршы” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, кулланылган троплар. Шигырьдә күтәрелгән проблема.
**Туфан Миңнуллин.** Тормыш юлы турында мәгълүмат. “Акбай һәм Кыш бабай” пьесасы**.** Пьесада Яңа ел бәйрәменә әзерлекнең бирелеше. Кыш бабай белән Кар кызы теләкләре. Яңа ел белән котлау сүзләре.
**5. Акыл — тузмас кием, белем — кипмәс кое (5)**
**Каюм Насыйри.** Әдип турында кыскача белешмә. Аның энциклопедист галим булуы. Казандагы һәм Яшел Үзән районындагы музейлары. “Әбүгалисина” кыйссасы. Әбүгалисина һәм Әбелхарис образлары. Аларның белемгә омтылышлары, белем өйрәнүдәге тырышлыклары. Белемнең файдасы. Әбүгалисинаның ярлы егеткә, Әбелхарисның патшага булышуы. Туганлык һәм көнчелек хисләре. Әбүгалисинаның галим булып танылуы.
**Абдулла Алиш.** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. “Әни ялга киткәч” хикәясе. Хикәянең төп идеясе. Малайның яңага омтылышы, эшчәнлеге. Малайның өйдә башкарган эшләре. Малайның эшкә өйрәнүе турындагы мәкальләр.
**Фәнис Яруллин.** Әдип турында кыскача белешмә. **“**Кояштагы тап” хикәясе**.** Әсәрнең төп идеясе. Малай һәм ана образлары. Хикәядә ялганның, ялкаулыкның фаш ителүе. Яманлыкның эзе калуы.
**Гөлшат Зәйнашева.** Шагыйрә турында кыскача мәгълүмат. “Кем булырга?” шигыре**.** Шагыйрәнең әйтергә теләгән фикере. Шигырьдә әйтелгән һөнәрләр. Һөнәр сайлауның мөһимлеге.
**Салих Сәйдәшев.** Композиторның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы, музее, һәйкәле.
**6. Ил өстендә илле дустың булсын (2)**
**Дәрдемәнд.** Әдип турында кыскача белешмә. “Ике туган” хикәясе**.** Хикәянең эчтәлеге. Туганлык мөнәсәбәтләренең бирелеше. Сәламәт булуның, куркынычсызлыкның элементар кагыйдәләре.
**Һади Такташ.** Шагыйрь, аның балачагы турында мәгълүмат. **“**Мокамай” поэмасы. Поэманың эчтәлеге. Мокамай образының прототибы. Поэмада кулланылган сурәтләү чаралары. Тормыштагы ялгыш адымның һәлакәткә илтүе. Шагыйрьнең дуслык хисләренә тугрылыгы. Поэмадагы символлар. *Әдәбият теориясе. Поэма.*
**Эльмира Шәрифуллина.** Шагыйрә турында кыскача мәгълүмат. “Дуслык, чын дуслык!” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, төзелеше. Дуслыкның көче турында уйлану.
**7. Көлке көлә килә... (2)**
**Шәүкәт Галиев.** “Курыкма, тимим”, “Атлап чыктым Иделне” шигырьләре**.** Шигырьләрнең эчтәлекләре. Һәр шигырьдәге юмор.

**Фаил Шәфигуллин.** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. “Ике тиен акча” хикәясе. Хикәянең эчтәлеге. Марат образы. Хикәядәге юмор. Язучының юмор аша әйтергә теләгән фикере.

**8. Һәр фасылың гүзәл, табигать! (4)**

**Гәрәй Рәхим.** Шагыйрь турында кыскача мәгълүмат. “Апрель” хикәясе**.** Әсәрнең эчтәлеге. Төп идеясе. Хикәядәге чагыштырулар. Автор игътибарны юнәлткән табигать кануны.

*Әдәбият теориясе. Портрет.*

**Гомәр Бәширов.** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. **“**Туган ягым – яшел бишек” повестеннән өзек. Сабантуй турындагы өзекнең эчтәлеге. Сабантуй бәйрәменең тасвирлап бирелеше. Көрәшче егетләр, Хәкимҗан образлары. Сурәтләү чаралары. Сабантуй бәйрәме тарихы.

**Лотфулла Фәттахов.** Рәссамның тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. “Сабантуй” картинасында сурәтләнгән табигать, авыл кешеләре.

**Балалар өчен чыга торган газета-журналлар. “Сабантуй” журналы.** Журнал басылып чыгу тарихы. Журнал рубрикалары. Мәкаләләрнең эчтәлеге.

**Әдәби әсәрләр минимумы**

Г.Тукай, “Шүрәле”әкият-поэмасы,”Туган авыл” шигыре;

М.Гафури “Ана” шигыре;

Һ.Такташ, “Мокамай” шигыре;

М.Җәлил, “Чәчәкләр” шигыре;

Ә.Еники, “Туган туфрак” (өзек);

Г.Бәширов, “Сабантуй” (өзек).

**Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

Уен җырлары

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны

Н.Исәнбәт. “Өч матур сүз” шигыре

М.Җәлил. “Чәчәкләр” шигыреннән өзек

Р.Вәлиева. “Нәни чыршы” шигыре

Э.Шәрифуллина. “Дуслык, чын дуслык!” шигыре

Эш программасын тормышка ашыру өчен Россия Федерациясенең Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләр исемлегендә түбәндәге дәреслек күрсәтелә: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 6нчы с-ф. Ике кисәктә. 1,2 нче кисәкләр / Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Э.Х.Гыйзәтуллина; [рәссамы Диләрә Нәүрүзова]. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2014.

Бу дәреслекнең ФДББС гриф тамгасы бар һәм ул Россия Федерациясенең Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләр исемлегенә кертелгән, Татарстанның Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан кабул ителгән.

## 7 нче сыйныф

**Кереш(1 сәгать)**

Кеше тормышында китап. Аңа мәдхия. Дания Гайнетдинованың “Галиҗәнап Китап” әсәре.

**Халык авыз иҗаты(3 сәгать)**

Риваять. Халык авыз иҗаты әсәреннән риваять жанры. Аның үзенчәлекләре.

“Болгар каласының корылуы турында”, “Сихерче кыз”, “Казан кайда корылган?” риваятьләре.

Р. Заһидуллинның “Казанның килеп чыгышы турында риваятьләр”, Э Турнерелиның “Казан кальгасы” картиналары.

Әдәбият теориясе. Риваять.

Легенда. Жанр үзенчәлеге. “Ярканат дөньяны ничек саклап калган?”, “Зөһрә йолдыз” легендалары. Тарихи чыганаклар белән бәйләнеш. Әдәбият теориясе. Легенда.

Эпос-дастаннар. “Җик-Мәргән” әсәре. Әдәбият териясе. Эпос-дастан.

Әдәбият теориясе. Мәкальләр. Әйтемнәр. Дөнья халыклары мәкальләре.

**Борынгы әдәбият (1 сәгать)**

Сәйф Сараи. Тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача белешмә. “Сөһәил вә Гөлдерсен” әсәре турында. Әсәрдән өзекләр уку. Борынгы әдәбиятта ике яшь йөрәк арасында туган мәхәббәтнең сурәтләнүе. Фаҗигале язмыш.

**XVIII йөз әдәбияты (1 сәгать)**

“Мәҗмугыл хикәят”тән “Солтан Мәхмүд Газнәви һәм үткен сүзле, зиһенле фәкыйрь хикәяте” әсәрләре. Патша белән вәзир, патша белән халык, вәзир белән халык арасындагы бәйләнеш. Явызлык һәм яхшылык көрәшенең хәйлә белән хәл ителүе. Солтанның (патшаның) җиңелүе яки гафу үтенүе. Әдәбият теориясе. Хикәят жанры.

**XIX йөз әдәбияты(2 сәгать)**

Закир Һади. Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача белешмә. “Мәгъсүм” хикәясеннән өзекләр. Мәдрәсәдә белем бирү. Балаларның рәнҗетелүләре. “Белем алу – энә белән кое казу” мәкалендәге фикер белән аваздашлык.

**XXйөз әдәбияты(8 сәгать)**

Габдулла Тукай. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә.”Моңсу бер тарих” истәлеге. Х. Казаковның “Бәләкәй Апуш”, В. Федоровның “ Өчиледән Кырлайга”, Х. Якуповның “Тукай апасы Газизә белән” картиналары.

“Милли моңнар” шигыре. Халык күңелендә яралып, авырлыкларда сыгылмаска көч бирүче, моңы белән йөрәкләрне тибрәтүче “Әллүки” көенә дан җырлау.

“Шагыйрь” шигыре. Әдипнең шагыйрьгә биргән бәясе. Салкыннарда туңдырмаучы, картларга да җылы бирүче шигырьләргә мәдхия. О. Хәбибуллинның “Тукай” портреты”, И Әхмәдиевнең “Тукай турында сюита” картиналары. Габдулла Тукайның Казандагы музее. Мәхмүт Хөсәен. “Тукай – шигъри кыябыз” поэмасы. Цикл турында төшенчә.

Әхмәт Фәйзи. Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Тукай” романыннан өзек. ”Җаек”. Шагыйрьнең Җаектагы авыр да, кызыклы да, шагыйрь булырга ярдәм иткән тормыш юлы. Бер үк вакытта якын да, ерак та булган туганлык мөнәсәбәтләре. Дуслык темасы.

Дәрдемәнд. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача белешмә. “Видаг” шигыре. Туган илдән аерылу сагышының бирелеше. Аз күләмле әсәрләрдә тирән мәгънә белдерү. “Бәллү”. Бишек җырының матур бер үрнәге. Ананың сабыена булган мәхәббәте чагылышы..

Галимҗан Ибраһимов. Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. ”Табигать» балалары” әсәреннән өзек. Хезмәт кешесен данлау. Табигать һәм аның балалары арасында бәйләнеш.. Татар халкында киң таралган өмәләр. Яшьләрнең активлыгы. А. Пластовның “ Печән өсте”, Р. Заһидуллинның “Печәнгә төшү”, картиналары. Әдәбият теориясе. Пейзаж.

**1920-1930 нчы еллар әдәбияты (1 сәгать)**

Һади Такташ. Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Алсу” поэмасы. Татар поэзиясенә “бәреп” кергән үзе усал, үзе сөйкемле Алсу образы. Поэманың яңалыгы. Әдәбият теориясе. Поэма жанры. Лирик һәм эпик поэма.

**Сугыш чоры әдәбияты (2 сәгать)**

Фатих Кәрим. Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Бездә – яздыр” шигыре. Әсәрдә сагыну хисләренең бирелеше. Җиңүгә ышаныч. “Кыңгыраулы яшел гармун” әсәре. Яралы сугышчы кичерешләре. Әсәрдә юмор. Халык авыз иҗаты әсәрләре булган җырлар белән аваздашлыгы. Ватанга мәхәббәт, җиңүгә ышаныч хисләре.

Ф. Кәрим турында багышламалар.(Х. Әюп, Р. Мостафин, Р. Харис).

Гадел Кутуй. “Рәссам” хикәясе. Сугыш барган шәһәрләрнең берсендә иҗат ителгән картина.

Аның партизан отрядындагы сугышчыларга тәэсире. Картинада сурәтләнгән ана һәм бала.

**Сугыштан соңгы әдәбият (8 сәгать)**

Сибгат Хәким. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Бакчачылар” поэмасы. Үз хезмәтен ярату, хезмәтнең уңыш китерүе өчен көрәшү.

Әмирхан Еники. Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Кем җырлады?” хикәясе.Бөек Ватан сугышы китергән фаҗигаләрнең берсе – өзелеп сөйгән ярларның аерылуы. Туктап торган кара-каршы поездда – бер-берсен күрә алмаган егет белән кыз. Сагыну хисенең бирелеше. Әсәрдә халык җырларыныд роле. Азатлык өчен барган канкойгыч сугыш.

“Мәк чәчәге” нәсере. Нәсер турында төшенчә.

Гомәр Бәширов. “Менә сиңа мә!” хикәясе. Бөек Ватан сугышы яраларының бүгенге көндә дә сизелүе. Ир һәм хатын мөнәсәбәтләренең катлаулылыгы. Дөреслек һәм ялган. Хыянәт һәм гафу итү. Татар хатынының сабырлыгы.

Ибраһим Гази. Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Йолдызлы малай” хикәясе. Фашистларның явызлыгы. Курку хисенең фашистларга карата нәфрәткә әверелүе. Үлем алдында калган малайның психологик халәте.

Рашат Низами. “Блокада хатирәсе” әсәре. Ленинград блокадасы. Мәңге онытылмаслык хатирәләр.

**1960-1980 нче еллар әдәбияты (3 сәгать)**

Мөхәммәт Мәһдиев. Язучының томыш юлы һәм иҗаты турында белешмә.

“Без – 41 нче ел балалары” повестеннан өзек. Яязучының үзе күргән-кичергән вакыйгаларга нигезләнеп язуы. Балачагы балачаксыз үткән кичәге мәктәп укучыларының, педучилищеда белем алып, егет булып җитешү еллары. Сугыш китергән авырлыклар. Җор, үткен тел белән язылган повесть. Әдәбият теориясе. Повесть жанры.Автобиографик әсәр, троплар, метонимия.

М. Мәһдиев турында – язучылар. Мөхәммәт Мәһдиев музее.

Габдрахман Әпсәләмов. Язучының иҗаты һәм тормыш юлы турында белешмә. “Миңа 19 яшь иде” повесте. Һәлак булган кеше авызыннан сөйләнгән хикәяләү. Туган ил азатлыгы өчен барган сугыш. Илен яклап һәлак булган солдатлар. Мәңге 19 яшьтә калган батыр. Г. Әпсәләмов турында С. Хәкимнең “Батырлыкка чакырган кеше” язмасы.

Туфан Миңнуллин. Драматургның тормыш юлы һәм иҗаты. “Монда тудык, монда үстек” драмасы. Әдәбият теориясе. Драма әсәре.

**Хәзерге әдәбият ( 2сәгать)**
Марсель Галиев “Нигез” повестеннан өзек.
Ф. Урманче.”Нигез” повесте турында.
Гамил Афзал “Акыл, намус, белем” шигыре. Равил Фәйзуллин “Бердәнбер” шигыре.
**Фантастик әсәрләр (1 сәгать)**
Адлер Тимергалин. “Сәер планетада” әсәре. Язучы фантазиясе. Малайның серле планетага сәяхәте.
Әсәрдә фантастика һәм чынбарлык.
Әдәбият теориясе. Фантастика.
**Тәрҗемә әсәрләр (2 сәгать)**
А. Пушкин. “Кышкы кич” шигыре (М. Садри тәрҗемәсе). “Мин яраттым Сезне!” шигыре (Н. Акмал тәҗрибәсе).
Лена Шагыйрьҗан. «Минем дә үз Пушкиным бар...” Тәрҗемә эше турында фикерләр.
М. Лермонтов “Болытлар” шигыре (Ә. Давыдов тәрҗемәсе). Болытларга карап уйланулар.
Эчке монолог. Кабатлау һәм йомгаклау.
**Әдәби әсәрләр минимумы**
**М. Галиев**. “Нигез” (өзек). 2 нче бүлек.
**Бәйләнешле сөйләм үстерү**
Казанның килеп чыгышы турында риваятьләр.
Х. Казаков. “Бәләкәй Апуш” картинасы. Г.Тукайның Казандагы музее.
“Кем җырлады?” хикәясе буенча сочинение.
“Мин туган нигез”.
**Ятлау өчен тәэдим ителгән әсәрләр**
Г.Тукай. “Милли моңнар”;
Һ.Такташ. “Алсу” (өзек);
Ф.Кәрим. “Кыңгыраулы яшел гармун” (өзек)

8 нче сыйныф

1. **Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана (3)**

Халык авыз иҗаты, риваять жанры.
Халыкның борынгыдан килгән йолалары.БСҮ Үткән тарихыбыз белән танышу.

2. **Без тарихта эзлебез (4)**

Ибн Фадлан һәм аның 921 – 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе. Габдулла Тукай иҗаты. “Пар ат” шигыренә анализ. **“**Пар ат”шигырен өйрәнү.
Б.Урманче иҗаты.

3. **Онытылмас еллар (6)**

Татар халык җыры “Герман көе”.*Фатих Кәрим иҗаты.“Ант”* шигыре. “Кыңгыраулы яшел гарун” поэмасы. **Туфан Миңнуллин иҗаты. “Моңлы бер җыр**” драмасы. Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар. Хат үрнәкләре. Бөек Ватан сугышы батырларының фронт хатлары.

4. **Әтинең зур бүреге иртә киелде (3)**

Клара Булатова иҗаты. «Башым иям» шигыре.Н.Әхмәдиев иҗаты. «Җиңү көне» шигыре, “Минем туган көнем” хикәясе. Ф.Сафинның иҗаты. “Тулганай” әсәре. *Рәзил Вәлиев иҗаты. «Ватаным» шигыре.*

5. **Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан! Аңлар өчен йөрәгенең олылыгын,**

**Туу кирәк кайчак безгә яңадан! (7)**
Шәриф Камал иҗаты.“Буранда” хикәясе. Сибгат Хәким иҗаты, “Әнкәй”, “Җырларымда телим” шигырьләре. Туфан Миңнуллин иҗаты, “Әнкәй” шигыре. Марсель Галиев иҗаты.“Су буеннан әнкәй кайтып килә шигыре”. Фоат Садриев иҗаты. “Таң җиле” әсәре.

6. **Көлсәң – көл, еласаң – ела! (4)**

Гамил Афзал иҗаты. “Юл газабы” хикәясе, “Тәвәккәл әби” шигыре. Зәки Нури иҗаты, пародия, эпиграммалар.
**7. Даһи гомере – халкы хәтерендә! (4)**

Р.Харис иҗаты. “Гармунчы” поэмасы. “Ике гөл” шигыре.
 Галия Кайбицкая иҗаты.

7. **Табигатьнең дә җаны бар (4)**

Айдар Хәлим иҗаты. “Өч аяклы ат” повесте.  “Ялкын” журналына сәяхәт. Татар матбугате белән танышу.

**Әдәби әсәрләр минимумы**

1) Г.Тукайның “Пар ат” шигыре;
2) Ш.Камалның “Буранда” новелласы;
3) С.Хәкимнең “Җырларымда телим” шигыре;
4) Г.Афзалның “Юл газабы” хикәясе;
5) Ф.Садриевның “Таң җиле” романыннан өзек;
6) Р.Харисның “Ике гөл” шигыре;
7) Т.Миңнуллинның “Моңлы бер җыр” драмасыннан өзек.

**Ятлау өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

Г.Тукайның “Пар ат” шигыреннән өзек.
Ф.Кәримнең “Ант” шигыре.
Р.Вәлиевнең “Ватаным” шигыре.
С.Хәкимнең “Җырларымда телим” шигыре.
Р.Харисның “Ике гөл” шигыре.
Сөйләшү тематикасы
Халыкның борынгыдан килгән йолалары.
Әдәбиятта һәм сәнгатьтә Тукай образы.
Язучылар, шагыйрьләр тормышында сугыш.
Илебезгә җиңү килде!
Ана – бөек исем...
Табигать – уртак йортыбыз.
Зәки Нури иҗаты, пародия, эпиграммалар.
Даһи гомере – халкы хәтерендә!
Р.Харис иҗаты. “Гармунчы” поэмасы. “Ике гөл” шигыре.
 Галия Кайбицкая иҗаты.
Табигатьнең дә җаны бар
Айдар Хәлим иҗаты. “Өч аяклы ат” повесте.
Проект эше яклау. “Ялкын” журналына сәяхәт.

9 нчы сыйныф

**1. Атадан улына чын мирас – сүздер (3)**

Халык авыз иҗаты. Дастаннар.Халык авыз иҗатының эпик жанры дастан  турында төшенчә. Дастаннарның төрләре. “Идегәй” дастаны. Аның төп герое. Дастанда тарихи шәхесләрнең сурәтләнүе. Әсәрдә ил белән идарә итү, халык язмышы мәсьәләсе.*Әдәбият теориясе. Халык авыз иҗаты. Дастан.*

Кол Гали язмышы. Аның “Кыйссаи Йосыф” поэмасы. Йосыфның язмышы. Туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр. Йосыф-Зөләйха мәхәббәте. Сюжетта кешеләрне ярату (гуманизм), гаделлек карашларының чагылышы.

Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**2. Мәхәббәт бер булса да, ике йөрәктә  яши (2)**

Сәйф Сараиның тормыш юлы һәм иҗаты. “Сөһәйл вә Гөлдерсен” әсәре. Әсәрдә үлемнән дә көчле мәхәббәт сурәтләнүе.

**3. Гөл үссә – җирнең күрке, кыз үссә – илнең күрке (7)**

Габделҗаббар Кандалыйның тормыш юлы һәмиҗаты. “Сахибҗамалга” поэмасы. Шагыйрьнең әдәбиятка алып килгән яңалыгы. Әсәрдә мәхәббәтнең чагылышы. Хатын-кыз гүзәллеген тасвирлауда шагыйрьнең табышлары.

Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында белешмә. ӘдипнеңКазан чоры иҗаты.“Татар кызларына” шигырендә күтәрелгән мәсьәләләр. Әсәрдә лирик геройның хисләрен

ачыклау. Г.Тукайның татар кызлары турындагы хыял-өметләре. Казан шәһәрендә Габдулла Тукай музее турында мәгълүмат.*Әдәбият теориясе. Антитеза.*
Фатих Әмирханның тормыш юлы һәм иҗаты. Әдипнең күпкырлы иҗаты. “Хәят” повесте. Төп каһарман образы. Аңа хас сыйфатлар. Бай татар зыялыларының гаилә тормышы һәм гореф-гадәтләре. Шул шартларда үскән татар кызының холкы тәрбияләнү, омтылыш-теләкләре чагылу. Рус дөньясы белән аралашып үскән яшь кешенең дөньяга һәм яшәү тәртипләренә карашында каршылыклар туу. Кеше психологиясен тасвирлауда авторның осталыгы.
Аяз Гыйләҗевның тормышы һәмиҗаты турында белешмә. Аның “Җомга көн, кич белән...” повесте. Әсәрдә Бибинур образының бирелеше. Бибинур әбинең изге күңеллелеге, шәфкатьлелеге. Авторның кешеләрдә яхшылык, игелеклелек кебек сыйфатларның кими баруына борчылуы. Повестьның А.Солжиницинның «Матрёнин двор» әсәре белән уртак һәм аермалы яклары. Әсәрнең сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләнеше .
Рөстәм Мингалим иҗаты. Шагыйрьнең прозасы. “Сап-сары күзләр” хикәясе. Сугыш чоры кешеләренең язмышы, тормышы сурәтләнеше.
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**4. Бер йөрәктә туган җыр икенче йөрәкне кузгата (4)**

*Әдәбият теориясе. Лирика. Пейзаж лирикасы.*
Ркаил Зәйдулла турында белешмә. “Буранда” шигырендә сурәтләнгән табигать күренеше. Шагыйрь хисләрен ачу юллары .
Мөхәммәт Мирза тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Иҗатына хас үзенчәлекләр. *Әдәбият теориясе. Күңел лирикасы*
Фирүзә Җамалетдинованың иҗаты. Аның “Ташлар”, “Кунак көткән кебек” шигырьләренең идея-проблематикасы.
Рәшит Әхмәтҗанов тормышы һәм иҗаты турында белешмә. “Сандугач керде күңелгә” шигырендә шагыйрь хисләренең чагылышы
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**1. Театр – яктылыкка, нурга илтә! (3)**

Галиәсгар Камал тормышы һәм иҗаты турында белешмә. Драматург каләменә хас сыйфатлар. “Беренче театр” комедиясендә конфликт һәм аның чишелеше, образларның үзенчәлекле якларын ачу.*Әдәбият теориясе. Сүз уйнату. Монолог.*
Беренче хатын-кыз татар артисткасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская иҗаты, театр сәнгатен үстерүдәге эшчәнлеге.
Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры турында белешмә.
Халисә Мөдәррисованың тормышы һәм иҗаты. “Бәйге хакы” повестеннан өзек белән танышу. Язучының кеше язмышы турындагы ачыш-табышлары. Артистлар тормышын яктыртудагы яңалыгы. Аның сәхнә әсәре булып уйналуы.
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**6. Мең шифага ия кулларда күпме язмышларның эзе бар... (5)**

Габдрахман Әпсәләмовның тормыш юлы һәм иҗаты. “Ак чәчәкләр” романында күтәрелгән проблемалар. Әсәрдә табиблар һәм шәфкать туташларының хезмәтен чагылдыру үзенчәлеге.*Әдәбият теориясе. Роман. Хронотоп.*
Саҗидә Сөләймановaның тормышы һәмязмышы турында белешмә. Әдинең шигъри осталыгы. Шагыйрәнең прозасы. Табиблар тормышын чагылдырган “Гөлбадран” повестеннан алынган “Дөнья бу!..” өзеге белән танышу. Сәламәтлек сагында торучы табибларның үз эшләренә һәм кешеләргә мөнәсәбәте. Медицинада хирург хезмәте турында сөйләшү.
Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**7. Укытучым! Синең бөек исемең (2)**

Йөрәгемдә мәңге сакланыр...
Мөхәммәт Мәһдиевнең тормыш юлы һәм иҗаты. Әдип каләменә хас сыйфатлар. “Фронтовиклар” романында укытучылар тормышын һәм эшчәнлеген чагылдыру үзенчәлеге. Төп герой Рушад образы.*Әдәбият теориясе. Тип.*
Вакыйф Нуриевның тормыш юлы һәм иҗаты. “Инша” хикәясендә Әкрәм образының бирелеше. Хикәядәге юморны аңлау.

**8. Авыр эшкә беләк бар, кыю эшкә йөрәк бар (8)**

Хәсән Сарьянның тормыш юлы һәм иҗаты. Иҗатында лиризм. “Әткәм һөнәре” повестенда яшь кеше образын ачу үзенчәлекләре, аларда әхлакый сыйфатларның бирелеше. Татар халкының борынгыдан килгән һөнәрләре турында белешмә бирү.

Илдар Юзеевның тормыш юлы һәм иҗаты. Аның шигъри һәм драматурглык осталыгы. “Таныш моңнар” поэмасында яшь кешенең тормыш юлын сайлауны чагылдыру.

Хисам Камаловның тормыш юлы һәм иҗаты. “Очучы” хикәясендә күтәрелгән проблемалар. Очучы һөнәре турында мәгълүмат бирү.

Мәдинә Маликованың тормыш юлы һәм иҗаты. “Казан каласы – таш кала” повестенда архитекторлар һөнәренә хас сыйфатларны чагылдыру үзенчәлеге.

**Ятлау өчен тәэдим ителгән әсәрләр**

Г.Утыз Имәни “Гыйлемнең өстенлеге турында”

(өзек). М.Җәлил “Җырларым” Ф.Кәрим “Ант”

**ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ**

**5 нче сыйныф**

| № | Бүлек темасы | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1. | Борын-борын заманда. | 5 |
| 2. | Әкият яздым, укыгыз... | 5 |
| 3. | Белем баскычлары. | 5 |
| 4. | Балачак — хәтерләрдә мәңге калачак... | 5 |
| 5. | Ватаным өчен. | 5 |
| 6. | Кояшлы ил – бәхет иле. | 5 |
| 7. | Кеше – табигать баласы. | 3 |
| 8. | Эш беткәч көләргә ярый. | 2 |
| | Барлыгы | 35 |

**6 нчы сыйныф**

| № | Бүлек темасы | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1. | Мифлардан чынбарлыкка | 2 |
| 2. | Халык моңнары: җырлата да, елата да... | 4 |
| 3. | Кадерле син, кеше-туганым! | 13 |
| 4. | Энҗе карлар явып үткән... | 3 |
| 5. | Акыл — тузмас кием, белем — кипмәс кое. | 5 |
| 6. | Ил өстендә илле дустың булсын. | 2 |
| 7. | Көлке көлә килә... | 2 |
| 8. | Һәр фасылың гүзәл, табигать! | 4 |
| | Барлыгы | 35 |

**7 нче сыйныф**

| № | Бүлек темасы | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Кереш | 1 |
| 2 | Халык авыз иҗаты | 3 |
| 3 | Борынгы әдәбият | 1 |
| 4 | XVIII йөз әдәбияты | 1 |
| 5 | XIX йөз әдәбияты | 2 |
| 6 | XX йөз әдәбияты | 8 |
| 7 | 1920-1930 нчы еллар әдәбияты | 1 |
| 8 | Сугыш чоры әдәбияты | 2 |
| 9 | Сугыштан соңгы әдәбият | 8 |
| 10 | 1960-1980 нче еллар әдәбияты | 3 |
| 11 | Хәзерге әдәбият | 2 |
| 12 | Фантастик әсәрләр | 1 |
| 13 | Тәрҗемә әсәрләр | 2 |
| | Барлыгы | 35 |

**8 нче сыйныф**

| № | Бүлек темасы | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Тарих китабында безнең өчен бик күп хатирәләр саклана. | 3 |
| 2 | Без тарихта эзлебез | 4 |
| 3 | Онытылмас еллар | 6 |
| 4 | Әтинең зур бүреге иртә киелде | 3 |
| 5 | Ана — изге, Ана — бөек, аңа — дан! Аңлар өчен йөрәгенең олылыгын, | 7 |
| 6 | Көлсәң – көл, еласаң – ела! | 4 |
| 7 | Даһи гомере – халкы хәтерендә! | 4 |
| 8 | Табигатьнең дә җаны бар | 4 |
| | Барлыгы | 35 |

**9 нчы сыйныф**

| № | Бүлек темасы | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Атадан улына чын мирас – сүздер | 3 |
| 2 | Мәхәббәт бер булса да, ике йөрәктә яши | 2 |
| 3 | Гөл үссә – җирнең күрке,<br>Кыз үссә – илнең күрке | 7 |
| 4 | Бер йөрәктә туган җыр икенче йөрәкне кузгата | 4 |
| 5 | Театр – яктылыкка, нурга илтә! | 3 |
| 6 | Мең шифага ия кулларда<br>Күпме язмышларның эзе бар... | 5 |
| 7 | Укытучым! Синең бөек исмең<br>Йөрәгемдә мәңге сакланыр... | 2 |
| 8 | Авыр эшкә беләк бар,<br>Кыю эшкә йөрәк бар | 8 |
| | Барлыгы | 34 |